КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 декабрь г.Казань № 1232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 июль, 605 нче; 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы; 2018 ел, 3 декабрь, 1077 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга, шулай ук балалар өстәмә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе турындагы нигезләмәнең 2.2 нче пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативларын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләр» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләп чыгару тәртибендә:

2.2 нче пунктының җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны» сүзләренә алыштырырга;

2.3 нче пунктының егерме беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативларын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләр» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе» сүзләренә алыштырырга.

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин